КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче Түбән Утар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

30.10.2023 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 28 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2023 елның 30 октябрендә узган гражданнар җыенында «2024 нче елда Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче Түбән Утар торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

1) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Утар торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунтны эшләү, ком нигезен урнаштыру, вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, сууткәргеч торбаларны җиһазлау, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 130 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 72 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 72 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче Түбән Утар торак пунктында халык җыенын үткән дип таныграа, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип таныргa.
2. «2024 нче елда Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Түбән Утар торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә дигән сорау буенча:
1) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Утар торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунтны эшләү, ком нигезен урнаштыру, вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, сууткәргеч торбаларны җиһазлау, килешү буенча эшләр өчен түләү) карарын кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/korsabash адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Курсабаш авыл җирлеге башлыгы

А.Р. Гыймадиев